# *Газизова Әминә Әхмәтгали кызы*



*Мин, Газизова Әминә Әхмәтгали кызы, 1931 нче елның 18 нче октябренда туганмын. Сугыш башланганны мин шул ук көнне белдем. Миңа ул вакытта бары тик 9 яшь кенә иде. Мине бик каты курку биләп алды. Әти-әниләр елаша башлады, хәсрәткә чумдылар. Бу бик авыр хәбәр иде безнең өчен. 1941 нче елның апрелендә олы абыем Арслангалине сугышка алдылар. Ул сугышка китүгә озак та тормый, әсирлеккә эләгә.*

*Әтине дә сугышка алдылар. Әти сугышка командир булып китә.Ките, 8 ай үткәч, үлгән хәбәре килә. Ул бу сугышта батырларча һәлак була. Безнең өчен авыр көннәр башланды. Көннәр буе колхоз эшендә эшләдек. Урак урдык, печән җыйдык. Җирдән бөртекләп борчак җыеп ашадык. Басудан черек бәрәңге җыеп ашадык. Сыерыбыз бар иде. Шуның сөте белән тукландык. Әниебез безгә яшәргә көч бирде. Кая булса, шуннан җыеп кычыткан, кузгалак, ат кузгалагы ашадык. Авылда башлангыч мәктәп бар иде. Шунда 6 класс укыдык. Язарга дәфтәр, укырга китап та юк иде. Иске китапларның юл арасына язып өйрәндек. Сугыш вакытында авылга Мәскәү шәһәреннән гаиләләре белән урыслар кайтып урнаштылар. Алар кеше тормый торган өйдә тордылар. Бер гаиләнең 4 баласы ачлыктан гөмбә ашап үлделәр.*

*Сугыш вакытында военный налог түләп тордык. Сугыштан соң да бик озак түләттерделәр. Бик күпне күрде башкайларыбыз.*

*Сугыш вакытындагы хезмәтебез өчен дәүләт безне “труженик тыла” медале белән бүләкләде. Сугыш беткәнне безгә басуда эшләгәндә килеп әйттеләр. Безнең абый сугыш беткәннән соң да 6 ел ярым хезмәт иткәч кенә кайтты.*

*Сугыштан соңгы елларда яшәү җиңел булмады. Бөтен эшне дә кул хезмәте белән башкардык.*

*Хәзерге яшьләргә бәхетле булып яшәүләрен телим. Сугышлар кабат булмасын иде. Дөньялар тыныч, имин булуын телим.*